ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ **КАРАР**

25 октябрь, 2023 ел № 27/11

Шәһәр Советының 2011 елның 25 августындагы 13/11 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 24 июлендәге 370-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

ҚАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2011 елның 25 августындагы 13/11 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезләмәгә (Шәһәр Советының 2015 елның 27 февралендәге 38/8, 2015 елның 9 ноябрендәге 3/5, 2017 елның 24 октябрендәге 20/6, 2018 елның 10 августындагы 26/10, 2018 елның 8 ноябрендәге 27/12, 2019 елның 23 маендагы 31/8, 2020 елның 18 мартындагы 38/6, 2021 елның 4 августындагы 8/10, 2022 елның 2 ноябрендәге 17/10, 2023 елның 5 маендагы 23/10 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 39 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Бина, төзелеш яисә корылма булган мәдәни мирас объектын хосусыйлаштыру конкурста сату һәм әлеге мәдәни мирас объектын сатып алучы затка объект биләгән һәм аннан файдалану өчен кирәкле җир участогын бер үк вакытта арендага бирү юлы белән гамәлгә ашырыла.»;

2) 41 пунктның өченче абзацында «хосусыйлаштыру турында Федераль закон нигезендә әлеге җир участогында урнашкан мәдәни мирас объектының милекчесе тарафыннан мондый объектны сату буенча конкурс шартларын үтәү срогына төзелгән җир участогын арендалау шартнамәсеннән тыш» сүзләрен өстәргә;

3) 10 бүлекне яңа редакциядә бәян итәргә:

«45. Мәдәни мирас объектлары реестрына кертелгән мәдәни мирас объектлары акционерлык җәмгыятенә яисә җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятькә

үзгәртелүче унитар предприятиенең мөлкәт комплексы составында, мондый объектларны акционер җәмгыятьнең устав капиталына кертем буларак кертү юлы белән, аукционда (сакланышы канәгатьләнерлек булмаган мәдәни мирас объектыннан тыш) яисә конкурста (сакланышы канәгатьләнерлек булмаган мәдәни мирас объектына карата) мәдәни мирас объектларын карап тоту һәм алардан файдалану таләпләрен, мондый объектларның сакланышын тәэмин итү, мондый объектлардан файдалануны тәэмин итү таләпләренә, мондый объектлардан һәм территорияләрдә тышкы реклама урнаштыру таләпләренә, шулай ук мәдәни мирас объектлары турындагы язмалар, билгеләр һәм мәгълүматны урнаштыру таләпләрен йөкләтү шарты белән хосусыйлаштырылырга мөмкин.

Мәдәни мирас объектлары реестрына кертелгән мәдәни мирас объектлары, сакланышы канәгатьләнерлек булмаган мәдәни мирас объектларыннан тыш, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан, «Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары арендалый торган күчемле һәм күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә, әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән таләпләр йөкләтелү һәм әлеге Нигезләмәнең 41.1 пунктындагы нигезләмәләрнеүтәү шарты белән, хосусыйлаштырылырга мөмкин.

45.1. Мәдәни мирас объектлары реестрына кертелгән мәдәни мирас объектын хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарда мондый объектны мәдәни мирас объектлары реестрына кертелгән мәдәни мирас объектларына кертү турында мәгълүмат булырга тиеш.

Мәдәни мирас объектлары реестрына кертелгән мәдәни мирас объектын хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарга «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законның 47.6 статьясында (алга таба - 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон) һәм Федераль законның 21 статьясында күрсәтелгән мәдәни мирас объекты паспортына (ул булган очракта) кертелгән мәдәни мирас объектлары реестрына кертелгән мәдәни мирас объектына саклау йөкләмәләре күчермәләре, Федераль законның 48 статьясындагы 8 пунктында каралган очракта − башка саклау документы күчермәсе һәм мәдәни мирас объекты паспорты (булган очракта) беркетелергә тиеш.

Мәдәни мирас объекты реестрына кертелгән мәдәни мирас объектын хосусыйлаштыру тәртибендә читләштерүне күздә тоткан шартнамәдә мөһим шарт булып мәдәни мирас объектлары реестрына кертелгән хосусыйлаштырыла торган мәдәни мирас объектына ия булуның мөһим шарты буларак, 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законның 47.6 статьясында каралган саклау йөкләмәләре таләпләрен үтәү буенча яңа милекченең бурычы булып саналган йөкләү, саклау йөкләмәләре булмаганда − күрсәтелгән Федераль законның 48 статьясындагы 8 пунктында каралган башка саклау документы таләпләре булырга тиеш.

Мондый шартнамәдә әлеге пунктта каралган мәдәни мирас объекты реестрына кертелгән мәдәни мирас объектын хосусыйлаштыруның җитди шартлары булмаган очракта, алыш-биреш әһәмиятсез булып тора.

46. Конкурста сату юлы белән сакланышы канәгатьләнерлек булмаган мәдәни мирас объектын хосусыйлаштырган очракта, конкурс шартлары түбәндәгеләрне күздә тотарга тиеш:

1) 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законның 47.6 статьясында каралган саклау йөкләмәсе белән билгеләнгән таләпләр, саклау йөкләмәсе булмаганда − әлеге Федераль законның 48 статьясындагы 8 пунктында каралган башка саклау документы белән билгеләнгән таләпләр;

2) мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклауга вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру функцияләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органы гаризасы белән мәдәни мирас объектын яисә аның билгеләнгән өлешен саклап калуга, шул исәптән реставрацияләүгә, башка таләпләр;

3) әлеге пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында каралган таләпләр нигезендә сатып алучының мәдәни мирас объектын саклап калу эшләрен башкаруга, реставрацияләү эшләрен дә кертеп, билгеле бер срокта проект документациясен әзерләүне тәэмин итү йөкләмәсе;

4) әлеге пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында каралган таләпләр нигезендә сатып алучының мәдәни мирас объектын саклап калу эшләрен башкаруны тәэмин итү йөкләмәсе.

Конкурска сакланышы канәгатьләнерлек булмаган мәдәни мирас объектын сатып алуга бер генә гариза бирелгән очракта, сату-алу шартнамәсе мондый зат белән төзелергә мөмкин.

Сакланышы канәгатьләнерлек булмаган мәдәни мирас объектын сатуның башлангыч (минималь) бәясе бер сум итеп билгеләнә. Сакланышы канәгатьләнерлек булмаган мәдәни мирас объектын сатып алу конкурсында катнашу өчен алдан түләү мондый мәдәни мирас объектының кадастр бәясенең 20 проценты күләмендә билгеләнә. Алдан түләнгән сумманың мөлкәтне сатып алу бәясеннән артыграк өлеше конкурста җиңүчегә кайтарыла.

Мондый мөлкәтне конкурста җиңүчегә тапшыру һәм аңа милек хокукын рәсмиләштерү конкурста җиңүче конкурс шартларын үтәгәнче Россия Федерациясе законнарында һәм сату-алу шартнамәсендә билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Әлеге Нигезләмәнең 45.1 пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән мөһим шартлардан тыш, мондый шартнамәдә түбәндәге мөһим шартлар булырга тиеш:

сакланышы канәгатьләнерлек булмаган мәдәни мирас объектының яңа милекчесенең конкурс шартларын вакытында һәм тулы күләмдә башкару вазыйфалары турында;

мәдәни мирас объектының яңа милекчесе тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 45.1 пунктындагы өченче абзацта каралган шартнамәне бозган очракта сату-алу шартнамәсен өзү турында.

Сакланышы канәгатьләнерлек булмаган мәдәни мирас объектын сату-алу шартнамәсе өзелгән очракта, әлеге пунктның унберенче абзацында күрсәтелгән нигезләр буенча, мәдәни мирас объекты мондый объект милекчесенә анын бәясен, шул исәптән бүленмәгән яхшыртуны да кертеп, кире кайтармыйча һәм сату-алу шартнамәсен үтәүгә бәйле чыгымнарны компенсацияләмичә, муниципаль милеккә кире кайтарылырга тиеш.

Сакланышы канәгатьләнерлек булмаган мәдәни мирас объектын сатуга конкурс үткәрелгәндә, әлеге Нигезләмәнең 7 бүлегендә күрсәтелгән мәгълүматлардан тыш, башлангыч бәяне күтәрү күләме ("конкурс адымы") күрсәтелә.

47. Конкурс шартларын үтәү срогы җиде елдан артмаска тиеш.

Конкурс шартларының үтәлешен раслаучы документ булып мондый объектның яңа хуҗасына мәдәни мирас объектларын саклау органы тарафыннан 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә бирелгән мәдәни мирас объектын саклап калу буенча башкарылган эшләрне кабул итү акты санала";

4) 55 пунктның икенче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Йөкләтү, шул исәптән ачык сервитут, аларны билгеләү турында тиешле карар кабул ителгән очракта, хосусыйлаштыру килешүенең мөһим шарты булып тора.».

2. Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев